ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан шәһәре

__ __29.05.2020________ ________63_________

2020 елда «Чыганакларга сәяхәт» XI республика конкурсын үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2022 елларга Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 21 июлендәге 522 номерлы карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасында эчке һәм күчмә туристлыкны үстерү, яшьләрне инновацияле туристлык проектларын тормышка ашыруга җәлеп итү, Татарстан Республикасының өстенлекле туристлык үзәкләрен үстерү максатларында боерык бирәм:

1. 2020 елда «Чыганакларга сәяхәт» XI республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.
2. Туристлык индустриясен үстерү бүлегенә (А.В.Софьина) Конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча эшне оештырырга.
3. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «2019 елда «Чыганакларга сәяхәт» X республика конкурсын үткәрү турында» 2019 елның 14 июнендәге 69 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип таныргa.
4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны рәис урынбасары Е.А.Барабановка йөкләргә.

Рәис С.Е. Иванов.

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2020 елның «29» 05.2020 63 номерлы боерыгы белән расланды

2020 елда «Чыганакларга сәяхәт» XI республика конкурсын үткәрү турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә 2020 елда «Чыганакларга сәяхәт» XI республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибен, Конкурста катнашучыларга, конкурс проектларына һәм аларны Конкурска тапшыру тәртибенә карата таләпләр, шулай ук Конкурс үткәрү вакытларын билгели.

1.2. Конкурсның максаты булып яшьләрне Татарстан Республикасының туристлык үзәкләрен үстерү һәм алга этәрү буенча инновацияле туристлык проектларын тормышка ашыруга җәлеп итү, газиз төбәкнең туристлык ресурслары, аның мәдәни һәм экологик ядкәрләре турында яшьләрнең хәбәрдарлык дәрәҗәсен арттыру аша ватанпәрвәрлек хисен тәрбияләү тора.

1.3. Конкурсның төп бурычлары:

Татарстан Республикасы территориясенә туристларны җәлеп итү буенча туризм, өлкә һәм мәдәни юнәлешле проектларны булдыру һәм пропагандалау;

Татарстан Республикасында эчке һәм күчмә туристлыкны үстерү;

талантлы яшьләрне ачыклау һәм туристлык өлкәсенә җәлеп итү.

1.4. Конкурсны оештыручы булып Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тора.

1.5. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 21 июлендәге 522 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасында каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## 2. Конкурста катнашу шартлары

2.1. Конкурста катнашу түләүсез, ирекле нигездә башкарыла.

2.2. Конкурста Татарстан Республикасы территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда (алга таба – белем бирү оешмалары) белем алучылар исәбендәге затлар, эшләүче яшьләр, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан яшьләрнең иҗтимагый оешмалары вәкилләре катнаша.

2.3. Конкурста катнашуга проектларны алга этәрү белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан да, дәгъва белдерүчеләрнең үзләре тарафыннан да гамәлгә ашырыла. Конкурста күмәк башкарылган эшләр катнашырга мөмкин.

Конкурста катнашу өчен эшләр бер яисә берничә номинациядә (ихтыярга карап) кабул ителә.

2.4. Конкурста 7 яшьтән 25 яшькәчә булган (25 яшен тутырган) физик затлар катнаша.

## 3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Конкурс бер этапта, 2020 елның 3 августыннан 30 ноябренә кадәр үткәрелә.

Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүмат Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru) (алга таба – Дәүләт комитеты сайты) конкурс проектларын кабул итә башлаганчыга кадәр 15 календарь көне узганчы урнаштырыла.

3.2. Конкурс проектларын Дәүләт комитетына тапшыру вакыты – 2020 елның 3 августыннан 9 октябренә кадәр.

Конкурс проектлары 420015, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, М.Горький урамы, 19 йорт (туристлык индустриясен үстерү бүлеге) адресы буенча турыдан-туры тапшырыла яки почта юлламасы итеп җибәрелә. Почта аша җибәргәндә конкурс проекты шулай ук флеш-җайланмага да саклана.

Конкурс проектының электрон версиясе Конкурсны оештыручының электрон адресына кабатлана – puteshestviekistokam@mail.ru

3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктчасында күрсәтелгән, үз вакытында тапшырылган, эчтәлеге һәм рәсмиләштерелеше шушы Нигезләмә таләпләренә туры килә торган конкурс проектлары Конкурста катнашуга кертелә. Конкурска Татарстан Республикасының билгеле бер туристлык юнәлешенә, туристлык үзәгенә, туристлык индустриясе объектына яисә тулаем туристлык комплексына бәйле булган, республиканың туристлык продуктын булдыруга, үстерүгә яисә камилләштерүгә, Татарстан Республикасына Россия һәм чит илләр туристларын җәлеп итүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәрне үз эченә алган конкурс проектлары тапшырыла.

3.4. Конкурс дүрт яшь төркемендә үткәрелә:

1) Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында катнашучыларның Конкурс проектлары (1-4 сыйныф укучылары, 7-10 яшьлекләр).

2) Төп гомуми белем бирү оешмаларында катнашучыларның Конкурс проектлары (5-8 сыйныф укучылары, 10-14 яшьлекләр).

3) Урта (тулы) гомуми белем бирү оешмаларында (9-11 сыйныф укучылары) һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларның (15-18 яшьлекләр) конкурс проектлары.

4) Югары белем бирү оешмалары студентларының һәм эшләүче яшьләрнең конкурс проектлары (19-25 яшьлекләр).

3.5. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә, аларның һәркайсы әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән яшь төркемнәренең берәрсенә туры килә:

1) «Татарстан Республикасында мин кая барырга теләр идем» темасына иң яхшы рәсем.

Әлеге номинациягә бу Нигезләмәнең 3.4 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән беренче яшь төркеменең конкурс проектлары кабул ителә.

Әлеге номинациядә коллектив эшләре генә катнаша ала. Бер сыйныфтан өчтән артык булмаган коллектив эше кабул ителә.

Әлеге номинациянең конкурс проекты Татарстан Республикасының истәлекле туристлык урыннарына багышланган рәсем һәм эссене үз эченә ала.

Эссе ирекле прозаик инша, фикер йөртүдән гыйбарәт, билгеләнгән тема буенча шәхси тәэсирләрне һәм күзаллауларны белдерә.

2) Иң яхшы мәдәни-танып-белү маршруты.

Әлеге номинациягә бу Нигезләмәнең 3.4 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән икенче яшь төркеменең конкурс проектлары кабул ителә.

Әлеге номинациядә 5 кешегә кадәр төркем тарафыннан башкарылган коллектив эшләре генә катнаша ала.

3) Туристлык төрләре буенча иң яхшы экскурсия маршруты – түбәндәге бүлекләр буенча:

авылча туристлык маршруты;

этнотуристлык маршруты;

актив туристлык һәм ял маршруты;

гастрономик туристлык маршруты.

Әлеге номинациягә бу Нигезләмәнең 3.4 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән өченче яшь төркеменең конкурс проектлары кабул ителә.

Әлеге номинациядә йә индивидуаль башкарылган, яисә 5 кешегә кадәр төркем тарафыннан башкарылган коллектив эшләре катнаша ала.

«Иң яхшы мәдәни-танып-белү маршруты», «Туристлык төрләре буенча иң яхшы экскурсия маршруты» номинацияләрендә тапшырылган конкурс проекты, күрсәтү объектларын сурәтләп, маршрутның карта-схемасы, экскурсиянең контроль тексты һәм «экскурсияче портфеле» белән, турыдан-туры экскурсия маршрутын үз эченә ала.

Экскурсия маршруты экскурсия төркеменә хәрәкәт итү өчен иң уңайлы юлдан гыйбарәт. Маршрут әлеге экскурсия өчен объектларны карауның, төркемне урнаштыру өчен мәйданчыклар булуның иң дөрес эзлеклелегенә карап төзелә.

Маршрут бурычларының берсе – экскурсия темасын булдыра алганча тулы итеп ачарга ярдәм итү. Маршрут төзүгә төп таләпләр – объектларны логистик эзлеклелек буенча күрсәтүне оештыру һәм теманы ачу өчен тамашачылар булуын тәэмин итү.

Экскурсиянең контроль тексты – экскурсантларга җиткерелә торган мәгълүматларның фәнни, актуальләштерелгән эчтәлеген үз эченә ала торган технологик документ. Контроль текст нигезендә экскурсия уздыручы зат экскурсоводның үзенчәлекләрен һәм мөмкинлекләрен чагылдыра торган һәм конкрет экскурсантларның мәнфәгатьләренә туры килә торган аерым текст төзи (чыганак: ГОСТ Р 50681-2010: Туристлык хезмәтләре күрсәтү. Туристлык хезмәтләре күрсәтүне проектлау).

«Экскурсияче портфеле» – экскурсияче тарафыннан экскурсияне үткәрү барышында кулланыла торган мәгълүмат материаллары тупланмасының (фотолар, документларның күчермәләре, география карталары, схемалар, картина репродукцияләре) шартлы атамасы (чыганак: ГОСТ Р 54604-2011. Россия Федерациясенең Илкүләм стандарты. Туристлык хезмәтләре күрсәтү. Экскурсия хезмәтләре күрсәтү. Гомуми таләпләр).

4) Туристлык өлкәсендә иң яхшы проект.

Әлеге номинациягә бу Нигезләмәнең 3.4 пунктындагы 4 пунктчасында күрсәтелгән дүртенче яшь төркеменең конкурс проектлары кабул ителә.

Әлеге номинациядә аерым башкарылган конкурс проектлары катнаша ала.

«Туристлык өлкәсендә иң яхшы проект» номинациясенә Татарстан Республикасына туристларны җәлеп итүгә бәйле конкурс проекты тапшырыла. Конкурс проекты түбәндәге темаларның берсенә тапшырыла:

Татарстан Республикасы муниципаль районына туристларны җәлеп итү;

Татарстан Республикасының туристлык потенциалын алга этәрү;

Татарстан Республикасының туристлык өлкәсен цифрлаштыру.

Конкурс проекты проектның төп идеясен, максатларын һәм бурычларын, максатларына ирешү стратегиясен һәм механизмнарын, чаралар планын/графигын, күздә тотылган финанс чыгымнарын, планлаштырылган нәтиҗәләрне, Татарстан Республикасы өчен үсеш перспективаларын күрсәтеп, проект тасвирламасын үз эченә ала.

5) Иң яхшы видео-экскурсия.

Әлеге номинациядә бу Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән беренче, икенче һәм өченче яшь төркемнәренең конкурс проектлары катнаша.

3.6. Конкурска түбәндәге материаллар тапшырыла.

«Иң яхшы мәдәни-танып белү маршруты», «Туристлык төрләре буенча иң яхшы экскурсия маршруты», «Туристлык өлкәсендә иң яхшы проект», «Иң яхшы видео-экскурсия» номинацияләре өчен:

билгеләнгән форма буенча анкета-гариза (әлеге Нигезләмәнең 1 нче, 2 нче кушымталары);

проект документлары, түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

басма материаллар: Word форматындагы текст (шрифт зурлыгы – 12, юллар арасындагы аралык – берле), текст күләме – 30 000 аралыклы басма билгесенә кадәр;

фото материаллары: PDF/JPG форматында (иң күбе – 15 фото);

CD/DVD дискларда һәм флеш-җайланмаларда аудио һәм видеоматериаллар;

«Татарстан Республикасында мин кая барырга теләр идем?» темасына иң яхшы рәсем номинациясе өчен:

билгеләнгән форма буенча анкета-гариза (әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы);

теләсә кайсы техникада А4/А3 форматында кәгазьдә төсле итеп, рәсем ясау чараларын (төсле карандашлар, буяулар, балавыз акбурлары) кулланып ясалган рәсем. Рәсем Конкурсның оештыру комитетына ике төрдә тапшырыла: оригинал әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән почта адресына тапшырыла; рәсем фотосы (кимендә 1920х1080 киңәйтелеп) яисә сканер аша күчертелгән эш әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән электрон адреска тапшырыла;

эссе кереш, төп, йомгак өлешләреннән тора. Эссенең күләме А4 форматындагы ике биттән артмаска тиеш.

Басма материалар кәгазьдә һәм электрон рәвешендә тапшырыла.

Тапшырылган документларның барлык текстлары да автор исеменнән, фамилиясеннән һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма атамасыннан башланырга тиеш.

Конкурс материаллары теләсә нинди чит телдә бары тик рус теленә тәрҗемәсе булган очракта гына тапшырыла ала.

3.7. Шушы Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән датадан соң тапшырылган конкурс материаллары каралмый һәм Конкурста катнашуга кертелми.

3.8. Конкурска тапшырылган барлык материаллар да кире кайтарылмый һәм рецензияләнми.

## 4. Конкурста сайлап алу тәртибе

4.1. Килгән конкурс проектларын бәяләү максатында Дәүләт комитеты тарафыннан Конкурс комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

4.2. Комиссиянең шәхси составы Дәүләт комитеты боерыгы нигезендә, республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасының туризм һәм иҗтимагый оешмалары, фәнни бергәлек вәкилләреннән 12 кешелек составта, комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм җаваплы сәркатибе җитәкчелегендә раслана.

4.3. Комиссия эшенә рәис җитәкчелек итә. Ул булмаганда аның вазыйфалары урынбасарына йөкләнә. Өстәмә рәвештә экспертлар җәлеп итү хокукын Комиссия үз ихтыярында калдыра. Конкурс нәтиҗәләре турында шәхсән мәнфәгатьле булган затлар Комиссия әгъзалары була алмый.

4.4. Комиссия эше утырышта гамәлгә ашырыла. Әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, утырыш тулы хокуклы булып санала. Комиссиянең җаваплы сәркатибе тавыш бирү хокукына ия түгел.

4.5. Комиссиянең җаваплы сәркатибе түбәндәге функцияләрне үти:

әлеге Нигезләмәнең 3.6-3.8 пунктларында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, материалларны кабул итә һәм терки, һәм аларның саклануын тәэмин итә;

Комиссия утырышын оештыра, документлар әзерли һәм беркетмә рәсмиләштерә.

4.6. Комиссия карары утырышта катнашкан әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм Комиссия утырышы уздырылган көнне беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта катнашучы комиссия әгъзалары, комиссия рәисе һәм җаваплы сәркатип тарафыннан кул куела. Тавышлар саны тигез булганда, рәиснең тавышы хәл иткеч булып санала.

4.7. Комиссия утырышы беркетмәсе әлеге Нигезләмәнең 5.10 пункты нигезендә конкурста җиңүчеләргә һәм дипломантларга бүләкләр тапшыру тантанасы уздырылган көнне Дәүләт комитеты сайтында урнаштырыла.

4.8. Конкурста катнашучы зат Конкурс нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, ул Комиссиягә карата апелляция бирергә хокуклы.

Апелляция язмача рәвештә ирекле формада Комиссия рәисе исеменә Комиссия беркетмәсе Дәүләт комитеты сайтында бастырып чыгарылганнан соң өч эш көне эчендә тапшырыла һәм Комиссия әгъзаларына җибәрелә.

Комиссия әгъзалары апелляцияләр килү чоры тәмамланган көннән соңгы 4 эш көне эчендә аларны карап тикшерә һәм коллегиаль рәвештә фикер алыша. Карар ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш туплау нигезендә кабул ителә һәм Комиссиянең катнашкан әгъзалары күпчелекне тәшкил иткәндә, легитимлы булып таныла. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисенең тавышы хәл итүле була. Комиссиянең җаваплы сәркатибе Комиссия карары нигезендә Комиссия утырышы көнендә беркетмә төзи. Беркетмәдә Комиссиянең һәр әгъзасының фикере һәм гомуми йомгак күрсәтелә:

апелляцияне канәгатьләндермәү һәм бастырып чыгарылган нәтиҗәләрне саклау турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне үзгәртү турында.

Беркетмәгә утырышта катнашучы комиссия әгъзалары, Комиссия рәисе һәм җаваплы сәркатибе кул куя.

Дәүләт комитеты беркетмәгә кул куелганнан соң өч календарь көне эчендә Конкурста катнашучыга аның апелляциясе буенча кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Апелляцияне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия карары иң соңгысы була, ул яңадан каралмый һәм суд тәртибендә шикаять кылынырга мөмкин.

## 5. Конкурста җиңүчеләр һәм дипломантлар

5.1. Конкурста җиңүчеләр һәм дипломантлар Конкурс комиссиясе утырышында билгеләнә. Комиссия Конкурста катнашучылар каршында бәяләү сәбәпләрен нигезләми.

5.2. Конкурсның һәр номинациясендә катнашучыларның яшенә карата һәр дүрт төркемнән өч җиңүче – 1, 2, 3 урын билгеләнә. Конкурсның һәр номинациясендә җиңүчеләр Дәүләт комитетының махсус дипломнары һәм истәлекле призлары белән бүләкләнә.

5.3. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү 10 баллы шкала буенча катнашучыларның конкурс проектларының сыйфатын бәяләү критерийларына нигезләнеп башкарыла (әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасы).

5.4. Һәр критерий буенча Конкурс комиссиясе әгъзасы 10 баллы шкала буенча билге куя. Һәр критерий буенча билгеләр суммасы Конкурста катнашучыга гомуми билгене бирә.

5.5. Гариза составындагы материалларны эшкәрткәндә һәм анализлаганда, аларның объектив булу-булмавын бәяләгәндә Конкурс комиссиясе әгъзалары балл кую процессында үзара ышану, шәхсән җаваплылык һәм таләпчәнлек принципларыннан чыгып эш итә (1 балл – иң түбән билге, 10 балл – иң югары билге).

5.6. Конкурс йомгаклары турындагы карар Конкурс комиссиясе тарафыннан балларның гомуми суммасы буенча һәм шушы Нигезләмәнең 4.6 пунктына туры китереп кабул ителә.

5.7. Конкурс комиссиясе, әгәр Конкурска Конкурс таләпләренә тулы дәрәҗәдә җавап бирә торган конкурс проектлары тапшырылмаса, бер яисә берничә призлы урынны бирмәү хокукын үз ихтыярында калдыра.

5.8. Конкурсны оештыручы белән алдан килештереп, мәнфәгатьле оешмалар тарафыннан үткәрелүче Конкурс кысаларында катнашучыларга махсус казанышлар өчен өстәмә призлар һәм бүләкләр тапшырыла.

5.9. Конкурс нәтиҗәләре Конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсе нигезендә, аңа имза салынган көннән соңгы эш көннәрендә исәпләнүче 3 көнлек чорда Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

5.10. Конкурс йомгаклары Конкурста җиңүчеләргә һәм дипломантларга бүләкләр тапшыруның Дәүләт комитеты тарафыннан (аерым сценарий нигезендә) оештырыла торган тантанасында 2020 елның 30 ноябреннән соңга калмыйча җиткерелә.

Конкурс нәтиҗәләре турында игълан Дәүләт комитеты сайтында конкурста җиңүчеләргә һәм дипломантларга бүләкләр тапшыру тантанасы уздырылган көнне бастырыла.

5.11. Конкурсны оештыручы түбәндәгеләрне үз ихтыярында калдыра:

тапшырылган конкурс проектларын үзәк, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару хокукын;

материалларны челтәрләрле теле- һәм радиокомпанияләрнең эфирларында урнаштыру хокукын;

конкурста җиңүчеләрнең конкурс проектларын Дәүләт комитеты сайтында катнашучы авторлыгына сылтама белән бастырып чыгаруны.

5.12. Катнашучылар Конкурска үзләренең конкурс проектларын җибәрү факты белән әлеге Нигезләмәнең барлык шартлары белән дә тулысынча һәм берсүзсез риза булуларын раслый.

5.13. Катнашучылар Конкурска үзләренең конкурс проектларын җибәрү факты белән үзләренең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыкларын раслый.

---

2020 елда «Чыганакларга
сәяхәт» XI республика
конкурсын үткәрү турындагы
нигезләмәгә 1 нче кушымта

2020 елда «Чыганакларга сәяхәт» XI республика конкурсында катнашучыдан

АНКЕТА-ГАРИЗА

Номинация: «Иң яхшы мәдәни-танып-белү маршруты»
Номинация: «Туристлык төрләре буенча иң яхшы экскурсия маршруты»
Бүлек (аерып күрсәтергә кирәк)

- авылча туристлык маршруты
- этнотуристлык маршруты
- актив туристлык һәм ял маршруты
- гастрономик туристлык маршруты

| |
|---|
| 1. Тутыру датасы «_____» _____________ 2020 ел.<br><br>2. Катнашучының Ф.И.А. (тулысынча)<br>______________________________________________<br>______________________________________________<br><br>3. Яше ______________________________<br><br>4. Җитәкчесенең Ф.И.А.<br>______________________________________________<br>______________________________________________<br><br>5. Катнашучының яши торган адресы / белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешма адресы:<br>______________________________________________<br>______________________________________________<br>______________________________________________<br><br>6. Элемтә өчен телефоннар, электрон почта (e-mail)_________________________<br>______________________________________________<br><br>7. Катнашучы турында белешмәләр:<br>- белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешма атамасы /эш урыны һ.б. (тулысынча)<br>______________________________________________<br>______________________________________________<br>- өстәмә башка мәгълүматлар __________________________________________<br>______________________________________________<br>______________________________________________<br><br>8. Эш атамасы, кыскача аннотациясе<br>______________________________________________<br>______________________________________________ |
| 9. Конкурс комиссиясе йомгаклары |

2020 елда «Чыганакларга сәяхәт» XI
республика конкурсын үткәрү турындагы
нигезләмәгә 2 нче кушымта

2020 елда «Чыганакларга сәяхәт» XI республика конкурсында катнашучыдан

АНКЕТА-ГАРИЗА

Номинация (кирәклесен күрсәтергә)

- o Иң яхшы видео-экскурсия
- o Туристлык өлкәсендә иң яхшы проект.

1. Тутыру датасы «_____» _____________ 2020 ел.

2. Катнашучының Ф.И.А. (тулысынча)
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

3. Яше ________________________________

4. Җитәкчесенең Ф.И.А.
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

5. Катнашучының яши торган адресы / белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешма адресы: _____________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

6. Элемтә өчен телефоннар, электрон почта (e-mail)___________________________
_______________________________________________________________

7. Катнашучы турында белешмәләр:

- белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешма атамасы /эш урыны һ.б. (тулысынча)
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

- өстәмә башка мәгълүматлар ____________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

8. Эш атамасы, кыскача аннотациясе
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

9. Конкурс комиссиясе йомгаклары

2020
елда «Чыганакларга сәяхәт» XI республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта

2020 елда «Чыганакларга сәяхәт» XI республика конкурсында катнашучыдан

АНКЕТА-ГАРИЗА

Номинация: «Татарстан Республикасында мин кая барырга теләр идем» темасына иң яхшы рәсем.

1. Тутыру датасы «_____» _____________ 2020 ел.
2. Белем бирү оешмасының атамасы
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
3. Мәгариф оешмасы җитәкчесе Ф.И.А.
__________________________________________________________________________
4. Мәгариф оешмасы директорының Ф.И.А.
__________________________________________________________________________
5. Белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешманың урнашкан адресы: ___________
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
6. Җитәкченең элемтә өчен телефоннары, электрон почтасы (e-mail) ___________
__________________________________________________________________________
7. Конкурста катнашучылар турында мәгълүмат:
Сыйныфы _________________________________________________________________
8. Эшенең атамасы исеме, кыскача аннотациясе (эссе)
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________

9. Конкурс комиссиясе йомгаклары

2020 елда «Чыганакларга сәяхәт» XI республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 4 нче кушымта

Катнашучыларның конкурс проектларының сыйфатын бәяләү

критерийлары

| Критерий атамасы | Баллар | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Белдерелгән номинациягә туры килүе | | | | | | | | | | |
| Материалны бәян итү стиле, теле (аныклыгы, мантыйклыгы, лексикасы, грамматикасы) | | | | | | | | | | |
| Туристлык төшенчәләренә һәм терминнарына ия булуы | | | | | | | | | | |
| Конкурс проектының Конкурс турындагы нигезләмә таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән булуы | | | | | | | | | | |
| * «Экскурсияче портфеле» булу | | | | | | | | | | |
| * Экскурсиянең контроль тексты булу | | | | | | | | | | |
| * Маршрутның карта-схемасы булу | | | | | | | | | | |
| ** Җентекле икътисадый нигезләмә | | | | | | | | | | |
| *** Техник яктан гамәлгә ашыру (видеоязманың сыйфаты, видеороликны монтажлау, башкару катлаулылыгы) | | | | | | | | | | |
| **** Рәсемне сәнгатьле башкару | | | | | | | | | | |
| **** Теманы ачу (эчтәлеген тулыландыру) | | | | | | | | | | |

* «Иң яхшы мәдәни-танып-белү маршруты» һәм «Туристлык төрләре буенча иң яхшы экскурсия маршруты» номинацияләрендә бәяләнә

** «Туристлык өлкәсендә иң яхшы проект» номинациясендә бәяләнә

*** «Иң яхшы видео-экскурсия» номинациясендә бәяләнә

**** «Татарстан Республикасында мин кая барырга теләр идем?» темасына иң яхшы рәсем номинациясендә бәяләнә